ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 октября 2024 ел № 7079

Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2020 елның 3 августындагы 3706 номерлы, 2023 елның 18 маендагы 4068 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта:

- 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедурасы тәмамланган – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә, ул бюджетка түләүләр буенча түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бурыч өлешендә;»;

- 2.1 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки гаебен кичерү турында актларны кулланганда яки суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү

мөмкинлеген югалтуга нигез булган карар кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;»;

- 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешнең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча түләтүчегә башкару документын кире кайтарганда, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствосының тәмамлануы турында карар чыгарылганда, әгәр банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен, күләме бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләрдәге күләмнән артмаган бурыч барлыкка килгән датадан башлап биш елдан артык вакыт узган булса;»;

- түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пунктча өстәргә:

«5.1) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, суд тарафыннан банкротлык турындагы эш буенча производствоны туктату яки бурычлы затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару хакында акт кабул ителү;»;

2) 5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

«7) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки гаебен кичерү турында акт яки суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуга нигез булган карар кабул ителү, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;

8) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтару яки банкротлык турындагы эш буенча производствоны туктату турында суд акты.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев